РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**30.01.2025** Кукмара ш. **№ 82**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлегенигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «2025 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2025 елның 23 гыйнварындагы 33 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында» Кукмара муниципаль районы Советының 2024 елның 2 августындагы 261 номерлы карары нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 2025 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 9165,37 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.М. Әхмәтшинага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2025 елның 30 гыйнварындагы 82 номерлы карарына 1 нче кушымта

2025 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында җирләү буенча исемлектәге гарантияләнгән хезмәтләрнең бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3913,97 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетен) зиратка илтү | 1259,58 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3991,82 |
| Барлыгы | 9165,37 |

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2025 елның 30 гыйнварындагы 82 номерлы карарына 2 нче кушымта

2025 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында җирләү буенча исемлектәге гарантияләнгән хезмәтләрнең бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү (киендерү) | 164,78 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3749,19 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетен) зиратка илтү | 1259,58 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3991,82 |
| Барлыгы | 9165,37 |